*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 56**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кояш
   ә) колын
   б) урман
   в) үлән

2. [’] тартыгы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) яшьтәш
   ә) сәнгать
   б) төньяк
   в) мәсьәлә

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Кесә ягы сай***
   а) акчасы аз
   ә) акчасы күп
   б) авыру, аксак
   в) мактанчык

4. Тарихи сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) шартлама
   ә) инсан
   б) ясак
   в) дару

5. Тамырдаш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ил, иләк
   ә) тоз, тозак
   б) бас, баскыч
   в) кыз, кызчык

6. Охшату-чагыштыру рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) салмак

ә) мамыктай
б) кышын
в) юри

7. Билгеле үткән заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) җырлый
ә) җырлар
б) җырлаган
в) җырлады

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Калган эшкә кар явар*. (Мәкаль).
а) калган
ә) эшкә
б) кар
в) явар

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган авазны һәм сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

[ __ ] – тел уртасы тартыгы. Әйтелешләре яисә язылышлары бертөрле, ә мәгънәләре төрле булган сүзләр _________________ дип атала. Тамыр нигез һәм ___________ нигез була. Сыйфатлар исемнәрдән һәм ___________ ясала. Хикәя, шарт, боерык һәм теләк фигыль – __________ фигыльләр.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

*Ромашка – многолетнее растение. Это растение морозостойкое. Ромашка является королевой полей и лугов. Ромашку используют при простуде. На её основе делают шампуни и крем.*

2. Мәкальне укыгыз, биремнәрне башкарыгыз.

*Ялкауның көн дә башы авырта*. (Мәкаль)

2.1. [w] авазы булган сүзләрне языгыз. **(1 балл)**
2.2. *Ялкау* сүзенең антонимын языгыз. **(1 балл)**
2.3. Тартым белән төрләнгән исемне языгыз. **(1 балл)**
2.4. *Авырта* фигыленең заманын, зат-сан белән төрләнешен языгыз. **(3 балл)**
2.5. Җөмлә кисәкләрен билгеләгез. **(4 балл)**

3. Сез мәкальне ничек аңлыйсыз? Шул хакта 8 җөмлә языгыз. **(15 балл)**